| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>423962, Ютазы авылы,<br>Дмитров урамы, 2<br>тел. 4-00-91<br>факс: 8 (85593) 4-00-55 | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>423962 с. Ютаза,<br>ул. Дмитрова, д.2<br>тел. 4-00-91<br>факс: 8 (85593) 4-00-55 |
|---|---|


**ПРОЕКТ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1** **«29» гыйнвар 2025 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Керкәле торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 18 ноябрендәге 8 санлы;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ык торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 19 ноябрендәге 14 санлы;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 19 ноябрендәге 15 санлы;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Алма-Ата торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 19 ноябрендәге 10 санлы;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Малиновка торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 19 ноябрендәге 12 санлы;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пунктында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 22 ноябрендәге 18 санлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында түбәндәге

веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы: Л.М.Хәйруллина

Ютазы авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның
“29”гыйнварнын
1 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган һәр граждан, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2025 елның 22 гыйнварыннан 2025 елның 28 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкара.

3. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

8. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның “29” гыйнварнын 1 санлы карарына 2 нче кушымта

Ютазы авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ___________________________________________________________
Адресы: _________________________________________________________________________
______________________________________________________ нигезендә
________________________Сезгә __________________елның “___”_______________кадәр үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче ___________________________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Ютазы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ ____________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
___________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ___________________________________________________________
Адресы: ________________________________________________________________________
«__» _________________ 20__ елны ______________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.